ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Г.Тукая, д.35, д. Шемяк,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

Г.Тукай ур., 35 нче а йорт, Шәмәк авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-68-37; e-mail: Shmk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление　　　　　　　　　　Карар

«18» « сентябрь» 2019 ел　　　　　　　　　　№ 11

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р Б И Р Д Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Һәлак булган солдатка куелган Шәмәк һәм Иске Чәбия торак пунктларындагы һәйкәлне ремонтлау ( төзелеш материалы сатып алу, дивар салу, язулы мәрмәр табличкалар сатып алу, солдат скульптурасы астында пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү)
- Шәмәк һәм Иске Чәбия торак пунктларына янгын гидрантлары җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Шәмәк һәм Иске Чәбия торак пунктларындагы су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру;
-Шәмәк торак пунктында юллардагы чокырларны вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
- Шәмәк һәм Иске Чәбия торак пунктларындагы юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ »　　　　　　　　　　« ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /И.Н.Зиятдинов/